КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 31 июль г.Казань № 608

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүне оештыру турында» 2010 ел, 28 октябрь, 864 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 7 август, 674 нче, 2013 ел, 14 февраль, 103 нче, 2013 ел, 30 ноябрь, 936 нчы, 2014 ел, 9 июль, 479 нчы, 2016 ел, 27 сентябрь, 686 нчы, 2017 ел, 1 ноябрь, 830 нчы, 2017 ел, 12 декабрь, 976 нчы, 2019 ел, 23 июль, 618 нче, 2019 ел, 1 ноябрь, 997 нче, 2021 ел, 27 март, 177 нче, 2023 ел, 17 август, 983 нче, 2023 ел, 29 декабрь, 1752 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат үзәге турында нигезләмәгә, 2 пунктның алтынчы абзацында «һәм (яисә) территорияне төзекләндерү" сүзләрен "территорияне төзекләндерү, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халык инспекторы» дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2014 ел, 9 июль, 479 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 30 май, 441 нче, 2021 ел, 19 июль, 590 нчы, 2022 ел, 19 гыйнвар, 28 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендә» сүзләрен «юл хәрәкәте иминлеге һәм әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәләрендә» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслар министрлыгына, шулай ук Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына үз эшчәнлегендә «Халык инспекторы» дәүләт мәгълүмат системасын файдалануны һәм «Халык инспекторы» дәүләт

мәгълүмат системасы турындагы Нигезләмәгә таянып эш итүне тәкъдим итәргә.»;https://login.consultant.ru/link/?req=doc&base=RLAW363&n=162462&dst=100020

әлеге карар белән расланган «Халык инспекторы» дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәдә:

1.1 пунктта «һәм (яисә) территорияне төзекләндерү» сүзләрен «, территорияне төзекләндерү, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану» сүзләренә алмаштырырга;

1.2 пунктта «һәм территорияне төзекләндерү» сүзләрен «, территорияне төзекләндерү, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлектә:

өченче абзацта «территорияне төзекләндерү,» сүзләреннән соң «әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану,» сүзләрен өстәргә;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башкаручы - Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары;»;

3.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә административ хокук бозулар турында хәбәр итү өчен - әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә административ хокук бозу вакыйгаларының булуын дәлилли торган фотога төшерү һәм (яисә) видеоязма материаллары, кулланучы турындагы белешмәләр (Ф.И.А.и. һәм элемтә мәгълүматлары, яшәү урынын, телефон номерын һәм электрон адресын кертеп), алар кулланучы карамагы буенча бирелә. Җаваплыгы Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексының 8.2 статьясындагы 31 өлешендә каралган административ хокук бозу турында белешмәләр булган очракта ул шулай ук җитештерү һәм куллану калдыкларын төшереп калдыру яисә ташлау башкарыла торган автомототранспорт чарасы турында белешмәләр (марка, дәүләт теркәү номеры), шулай ук административ хокук бозу урынының территориаль координаталары (торак пункт исеме, урам исеме, йорт номеры) булырга тиеш.»;

3.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Хәбәрнамәләрне карау статусы үзгәргәндә, Кулланучы хәбәрнамәләрне электрон рәвештә карау нәтиҗәләре турында Мобиль кушымта аша хәбәр итә. Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексының 8.2 статьясындагы 31 өлешендә, 12.6 статьясында, 12.12 статьясындагы 1 һәм 2 өлешләрендә, 12.15 статьясындагы 4 өлешендә, 12.18 статьясында, 12.361 статьясында каралган административ хокук бозулар турында хәбәрнамәләр буенча Кулланучы административ хокук бозу турындагы эш законлы көченә кергән көннән алып 10 көн эчендә Мобиль кушымта аша электрон рәвештә хәбәрнамәләрне карау нәтиҗәләре турында хәбәр итә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин